РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
СТАРОКАРАМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423982, Р.Т. Муслюмовский район, с.Старые Карамалы, ул.Кооперативная 112а,*

*Иске Карамалы авылы* *« 22_» __04___ 2024 ел*

**Карар №11**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 19 нчы номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында («28» сентябрь 2021г. №24 үзгәрешләр белән)**

Федераль законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 19 нчы номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында («28» сентябрь 2021г. №24 үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

a. 2 бүлекнең 2.4 пунктындагы 2.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә:

« 2.4.1. Адреслашу объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, адреслашу объектына адреслашудан баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле мәгълүматны дәүләт адрес реестрында урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла:

а) кәгазьдә гариза бирелгән очракта - гариза килгән көннән соң 10 эш көненнән дә артык булмаган вакытта;

б) электрон документ формасында гариза бирелгән очракта - гариза кергән көннән соң 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта.";

1.2. 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 2.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карар әлеге объектка яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелә.»;

1.3. 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Гариза белән «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законның 35 статьясы яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә, адресация объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләрен яки комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы. »

1.4. 5 нче бүлекне 5.10 пункты белән тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.10. Дәүләт (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүнең аерым өлкәләрендә судка кадәр шикаятьләр "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (25.12.2023 ел редакциясе) гамәлгә ашырыла. »;

1.5. 1.5 пунктның 9 нчы абзацын яңа редакциядә бәян итергә:
«планлаштыру структурасы элементы;»;

1.6. 1.5 пунктның 10 нчы абзацын яңа редакциядә бәян итергә:
«урам-юл челтәре элементы урам, проспект, тыкрык, юл, яр буе, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Иске Карамалы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Л.М.Халиуллина**